


Мордовия Республикасы хәрби комиссары Игорь Тихомиров белән vткән брифинг темасы - Россия Кораллы кочләре сафларына язгы чакырылышны уздыру.

Игорь Тихомиров сvзләренә караганда, 2020 елгы язгы чакырылыш, алдагы еллардагы кебек vк, беренче апрельдә башланган һәм 15 июльдә тогәлләнәчәк.
“Коронавирус инфекциясенә каршы корәшнен заманча шартларында чакырылыш белән бәйле чаралар тозәтелде. Армиягә чакырылучылар белән әнгә мәләр телефон, видеоэлемтә аша vткәрелә. Хәзерге вакытта илнен Хәрби Кочләренә чакырылачак гражданнарны хәрби комиссариатларда, медицина һәм мәгариф оешмаларында булган документлар буенча ойрәнv алып барыла. Чакырылыш комиссияләре утырышлары май аена планлаштырылган, барысы да эпидемиологик хәлгә бәйле булачак”, - дип анлатты Мордовиянен Хәрби комиссары.
Ул ассызыклаганча, яз коне Россия Федерациясе Кораллы кочләренә Мордовиядән меннән артык кеше чакырылачак. хәрби хезмәткә чакы рылучыларнын  яраклылыгын исәпкә алып, гаскәрләрнен торләре буенча бvленәчәк. Шулай ук республиканын хәрби комиссариатында Краснодар хәрби училищесынын армия генералы С.М. Штеменко исемендәге фәнни ротасына һәм Кара дингез ярында урнашкан «ЭРА» хәрби инновацион технополисына кандидатлар сайлау vткәрелде. Биш кандидат сайлап алынган инде. “Фәнни роталарда хезмәт итvче егетләр vзләрен унай яктан гына кvрсәтте”, - диде Игорь Тихомиров.
Ул шулай ук республикада катлаулы эпидемиологик хәл шартларында хәрби хезмәткә чакырылучылар арасында коронавирус инфекциясе таралуга каршы корәш һәм кораллы кочләргә COVID-19 кертvне кисәтv буенча чаралар комплексы гамәлгә ашырыла, дип әйтте. “Жыелу пунктына килvче барлык призывниклар коронавирус инфекциясенә тест узачаклар. Хәрби комиссариатларда хәрби хезмәткә чакырылучыларны табиб-терапевтлар карап чыгачаклар, тән температурасы vлчәнеләчәк. Ботен транспорт дезинфекцияләнәчәк. Барлык призывникларга да шәхси саклану чаралары биреләчәк”, - дип сойләде Мордовиянен хәрби комиссары Игорь Тихомиров.
2020 елгы язгы чакырылыш кампаниясе барышында Мордовия хәрби комиссариатында «кайнар линия» телефоны эшли, ана хәрби хезмәткә чакырылуга кагылышлы сораулар бирергә момкин: 8-8342-38-55-14.

*Наилэ НАСЫРОВА*